РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Буа шәһәре

28 июнь 2024 ел № 4-62

ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә эшләүче сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләренә һәм хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законына, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль Законына, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа район Советының 2008 елның 29 февралендәге «ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә эшләүче сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләренә һәм хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү турында» 7-25 номерлы карарына (Буа район Советының 04.02.2011 ел, № 5-6, 31.07.2012 ел, № 13-21, 31.08.2012 № 8-22, 09.11.2012 № 7-25, 17.10.2013 № 10-35, 15.09.2017 № 16-24, 24.04.2018 № 10-31, 12.11.2020 № 9-3, 21.10.2022 № 5-35, 14.02.2023 № 5-40 ) (алга таба текст буенча карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башлыгына 37037 сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү һәм 138058 сум күләмендә айлык акчалата түләү билгеләргә.»;

1.2. карарның 2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгы урынбасарына 33331 сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү һәм 62971 сум күләмендә айлык акчалата түләү билгеләргә.»;

1.3. карарның 4 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» МКУ Рәисенә 33331 сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү һәм 62971 сум күләмендә айлык акчалата түләү билгеләргә.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап законлы көченә керә http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Камартдинов
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов